**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

423736, Татар Суксуы авылы, Гагарин урамы, 1 б нче йорт.
Тел. 3-44-60
e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423736, село Татарские Суксы,
ул. Гагарина, дом 1 б.
Тел. 3-44-60
e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
04 октября 2024 года

КАРАР
№14

Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитетының
2015 елның 10 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган,
Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 01 декабрендәге 2151 номерлы карары нигезендә, Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 10 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Федераль законның 82 статьясы нигезендә сатып алулар гамәлгә ашырылган очракта план-графикка үзгәрешләр кертү сатып алуларда катнашучыларга котировкалар бирү турында гарызнамә җибәрелгән көннән дә соңга калмыйча, ә Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты нигезендә бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алу башкарылган очракта - контракт төзелгән көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»

1.2. 11 пунктны РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 30 сентябрендәге «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау тәртибен билгеләү, мондый план-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графикларын урнаштыру, мондый план-графикларга мәгълүмат кертү үзенчәлекләре һәм сатып алу план-графиклары формасына таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 1279 номерлы карары нигезендә үз көчен югалткан дип таныырга.

1.3. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. План-график Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый планнарга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графикларын урнаштыру, мәгълүматны сатып алуларның план-графикларына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүнең план-графигы формасына карата таләпләр нигезендә формалаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http//pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татар Суксуы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Г.Г. Хамматуллина